МИНИСТЕРСТВО
ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

____10.12.2025____ г. Казань № __под-2025/25___

Халыкара татар теле олимпиадасын
үткәрү турындагы нигезләмәне раслау
хакында

2020 елның 10 сентябрендәге 821 номерлы «Татарстан Республикасының дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасындагы башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасын үтәү йөзеннән б о е р а м:

1. Кушымта итеп бирелгән Халыкара татар теле олимпиадасын үткәрү турындагы нигезләмәне расларга.
2. Милли мәгариф идарәсенә (А.С.Шәрипова) Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектларындагы мәгариф оешмаларына мәгълүмат җиткерүне тәэмин итәргә.
3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшерүне министр урынбасары М.З.Закирова җаваплылыгына йөкләргә.

Министр И.Г.Һадиуллин

**Татарстан Республикасы**
**Мәгариф һәм фән**
**министрлыгы**
**боерыгы белән расланды**
**« 10 » 12___ _2025___ ел**
**№ под-2025/25___________**

## Халыкара татар теле олимпиадасын үткәрү турындагы нигезләмә

### I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Халыкара татар теле олимпиадасын үткәрү турындагы әлеге нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) Халыкара татар теле олимпиадасын (алга таба – Олимпиада) оештыру һәм үткәрү тәртибен билгели.

1.2. Олимпиада Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 10 сентябрендәге 821 номерлы «Татарстан Республикасының дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасындагы башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасын раслау турындагы» карары белән расланган «Татарстан Республикасының дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасындагы башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасын (алга таба – Дәүләт программасы) гамәлгә ашыру кысаларында үткәрелә.

1.3. Олимпиаданың оештыручысы – Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы (алга таба – Министрлык).

1.4. Олимпиада ел саен Министрлык боерыгы белән билгеләнгән вакытта үткәрелә. Министрлык боерыгы Министрлыкның сайтында әлеге Нигезләмәнең 5.4 пунктында билгеләнгән Олимпиаданың дистанцион этабы башланган көннән алып 10 календарь көненнән дә соңга калмыйча урнаштырыла.

### II. Олимпиаданың максаты һәм бурычлары

2.1. Олимпиаданың максаты – Татарстан Республикасында һәм Россия Федерациясенең татарлар күпләп яши торган башка субъектларында, шулай ук чит илләрдә татар теле һәм әдәбиятын, татар мәдәниятен саклау һәм үстерүне яклау өчен өстәмә шартлар тудыру, татар телен өйрәнүгә һәм белүне камилләштерүгә мотивацияне арттыру һәм кызыксынуны көчәйтү, укучыларда һәм студентларда татар мәдәниятына һәм тарихына хөрмәтле һәм сакчыл мөнәсәбәт тәрбияләү, эрудицияне һәм лингвистик сәләтләрне үстерү.

2.2. Олимпиада бурычлары:

Татарстан Республикасы, Россия Федерациясе субъектлары һәм чит илләр мәгариф оешмаларында укучыларның һәм студентларның татар теле һәм татар әдәбиятын өйрәнүгә танып-белү кызыксынуын арттыру;

әдәби эрудициягә, татар теле һәм әдәбиятын, аның традицияләрен, мәдәният һәм сәнгатен белүче сәләтле укучыларны һәм студентларны ачыклау һәм яклау;

Россия Федерациясе субъектларында һәм чит илләрдә татар мәдәниятын халыкара гуманитар элемтәләрне ныгыту чарасы буларак популярлаштыру;

яшь буында туган телгә, татар мәдәниятенә мәхәббәт тәрбияләү;

укучыларның һәм студентларның иҗади сәләтләрен үстерү; фәнни-тикшеренү эшчәнлегенә кызыксынуны арттыру, татар теленә аңчыл һәм сак караш тәрбияләү.

## III. Олимпиада катнашучылары

3.1. Олимпиадада катнашучылар булып торалар:

тиешле уку елында туган (татар) тел һәм туган (татар) әдәбияты буенча республика олимпиадаларының йомгаклау этабы җиңүчеләре һәм призерлары арасыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре гомуми белем бирү оешмаларының 8-11 сыйныф укучылары;

тиешле уку елында Министрлык тарафыннан оештырылган татар теле буенча Төбәкара олимпиаданың җиңүчеләре һәм призерлары арасыннан Россия Федерациясенең башка субъектлары гомуми белем бирү оешмаларының 8-11 сыйныф укучылары;

Олимпиаданың дистанцион этабы нәтиҗәләре буенча Россия Федерациясе субъектларындагы (Татарстан Республикасыннан тыш) татар иҗтимагый оешмалары каршындагы якшәмбе мәктәпләре укучылары;

Олимпиаданың дистанцион этабы нәтиҗәләре буенча чит ил укучылары һәм студентлары;

Олимпиаданың дистанцион этабы нәтиҗәләре буенча һөнәри белем бирү оешмалары һәм югары белем бирү мәгариф оешмалары студентлары.

3.2. Олимпиадада катнашучылар категорияләре:

рус телендә белем бирүче Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларының татар телен туган тел буларак өйрәнүче 8 сыйныф укучылары;

рус телендә белем бирүче Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларының татар телен Татарстан Республикасының дәүләт теле буларак өйрәнүче 8 сыйныф укучылары;

туган (татар) телдә белем бирүче Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларының 8 сыйныф укучылары;

рус телендә белем бирүче Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларының татар телен туган тел буларак өйрәнүче 9 сыйныф укучылары;

рус телендә белем бирүче Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларының татар телен Татарстан Республикасының дәүләт теле буларак өйрәнүче 9 сыйныф укучылары;

туган (татар) телдә белем бирүче Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларының 9 сыйныф укучылары;

рус телендә белем бирүче Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларының татар телен туган тел буларак өйрәнүче 10 сыйныф укучылары;

рус телендә белем бирүче Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларының татар телен Татарстан Республикасының дәүләт теле буларак өйрәнүче 10 сыйныф укучылары;

туган (татар) телдә белем бирүче Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларының 10 сыйныф укучылары;

рус телендә белем бирүче Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларының татар телен туган тел буларак өйрәнүче 11 сыйныф укучылары;

рус телендә белем бирүче Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларының татар телен Татарстан Республикасының дәүләт теле буларак өйрәнүче 11 сыйныф укучылары;

туган (татар) телдә белем бирүче Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларының 11 сыйныф укучылары;

Россия Федерациясенең башка субъектлары гомуми белем бирү оешмаларының 8 сыйныф укучылары;

Россия Федерациясенең башка субъектлары гомуми белем бирү оешмаларының 9 сыйныф укучылары;

Россия Федерациясенең башка субъектлары гомуми белем бирү оешмаларының 10 сыйныф укучылары;

Россия Федерациясенең башка субъектлары гомуми белем бирү оешмаларының 11 сыйныф укучылары;

Россия Федерациясе субъектларының (Татарстан Республикасыннан тыш) якшәмбе мәктәпләре укучылары;

татар филологиясе юнәлеше буенча белем алучы һөнәри белем бирү оешмалары һәм югары белем бирү мәгариф оешмалары студентлары;

татар филологиясе юнәлеше буенча белем алмаучы һөнәри белем бирү оешмалары һәм югары белем бирү мәгариф оешмалары студентлары;

чит ил укучылары һәм студентлары.

## IV. Олимпиаданың оештыру комитеты һәм жюри

4.1. Олимпиаданы оештыру өчен Олимпиаданың оештыру комитеты (алга таба – Оештыру комитеты) төзелә. Олимпиада Оештыру комитеты составы Министрлык вәкилләреннән кимендә җиде кеше, «Татарстан Республикасы мәгариф үсеше институты» дәүләт автоном өстәмә һөнәри белем бирү учреждениесе һәм «Республика олимпиада үзәге» дәүләт автоном белем бирү учреждениесе вәкилләреннән кимендә ике кеше санында формалаша. Оештыру комитеты составы Министрлык боерыгы белән раслана.

4.2. Оештыру комитеты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

Олимпиаданы үткәрүнең оештыру-технологик моделен билгеләү;

Олимпиаданы үткәрү программасын эшләү, раслау, аның тормышка ашырылуын тәэмин итү;

Олимпиаданың дистанцион этабы һәм йомгаклау этабының жюри составын (алга таба – жюри) формалаштыру;

жюри эшен координацияләү;

әлеге Нигезләмәнең 3.2 пунктында күрсәтелгән Олимпиада катнашучыларының һәр категориясе буенча катнашучылар квотасын билгеләү;

әлеге Нигезләмәнең 3.2 пунктында күрсәтелгән Олимпиада катнашучыларының һәр категориясе өчен Олимпиаданың дистанцион этабы һәм йомгаклау этабы биремнәрен бәяләү өчен критерийларны һәм критерийлар буенча бәяләү кыйммәтләрен эшләү һәм раслау;

катнашучыларга олимпиада биремнәрен үтәү вакыты, үтәлгән олимпиада эшләрен рәсмиләштерү, үтәлгән олимпиада эшләрен күрсәтү, куелган баллар белән килешмәү турында апелляцияләр бирү һәм карау тәртибе, Олимпиададан

читләштерү нигезләре, шулай ук Олимпиада нәтиҗәләре белән танышу вакыты һәм урыны турында мәгълүмат бирү;

Олимпиада катнашучыларының олимпиада эшләрен кодлауны (шәхессезләндерү) һәм кодларны ачуны оештыру;

мәгариф өлкәсендә идарәчелек алып баручы җирле үзидарә органнарын, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектларының һөнәри белем бирү оешмалары һәм югары белем бирү мәгариф оешмалары җитәкчеләрен Олимпиада үткәрү вакыты һәм урыны турында мәгълүматландыру;

Олимпиада җиңүчеләре һәм призерлары квотасын билгеләү;

Гран-при иясе, Олимпиада җиңүчеләре һәм призерларын бүләкләүне оештыру;

Олимпиаданы оештыру һәм үткәрүгә кагылышлы башка мәсьәләләрне хәл итү.

4.3. Министрлык вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

Оештыру комитеты составын формалаштыру һәм раслау;

кимендә 30 кеше санында жюри составын формалаштыру һәм раслау;

республика һәм ведомство массакүләм мәгълүмат чаралары аша Олимпиаданың мәгълүмати яктыртылуын тәэмин итү;

Олимпиада үткәрү һәм Гран-при иясе, Олимпиада җиңүчеләре һәм призерларын кызыксындыру өчен чыгымнар сметасын раслау.

4.4. Жюри вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

Олимпиаданың дистанцион һәм йомгаклау этапларында үтәлгән эшләрне бәяләү;

йомгаклау этабының язма турындагы үтәлгән олимпиада эшләрен күрсәтүне үткәрү;

апелляцияләр карау нәтиҗәләрен исәпкә алып һәм Оештыру комитеты билгеләгән квотага туры китереп, катнашучылар рейтингы нигезендә Гран-при иясе, Олимпиада җиңүчеләре һәм призерларын билгеләү;

Олимпиаданың йомгаклау этабының язма туры, телдән туры һәм проект яклау протоколлары нигезендә йомгаклау протоколын рәсмиләштерү;

Министрлыкка Олимпиада нәтиҗәләре белән җиңүчеләр, призерлар һәм Олимпиада катнашучылары рейтинг таблицасы формасында рәсмиләштерелгән, жюри рәисе һәм сәркатибе тарафыннан имзаланган жюри протоколын тапшыру;

Олимпиаданың йомгаклау этабы вакытында катнашучыларның эш шартлары өчен контрольне гамәлгә ашыру.

Олимпиаданың йомгаклау этабында катнашу өчен Олимпиада катнашучыларын әзерләгән жюри әгъзасы бу турыда Олимпиада башланганчы Оештыру комитетына хәбәр итә. Күрсәтелгән жюри әгъзасы, үзе Олимпиаданың йомгаклау этабында катнашырга әзерләгән катнашучыларның үтәлгән олимпиада эшләрен тикшерүдә, күрсәтүдә, шулай ук алар биргән апелляцияләрне карауда катнаша алмый. Әлеге абзацта күрсәтелгән таләпләрнең үтәлеше өчен контроль Оештыру комитетына йөкләнә.

4.5. Жюри составы Оештыру комитеты тарафыннан Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан һөнәри белем бирү оешмалары һәм югары белем бирү мәгариф оешмаларының педагогик һәм фәнни хезмәткәрләре арасыннан формалаштырыла.

4.6. Жюриның барлык карарлары Олимпиаданың йомгаклау этабының язма һәм телдән турлары, проектлар яклау протоколлары нигезендә кабул ителә. Һәр турдан соң жюри әгъзалары тарафыннан әлеге этапның протоколы төзелә, анда бирелгән катнашучылар категориясе белән эшләгән һәр жюри әгъзасының баллары кертелә. Тур өчен уртача балл Олимпиаданың йомгаклау этабының йомгаклау протоколына кертелә. Йомгаклау протоколы язма, телдән турлар һәм проектлар яклау өчен баллларны үз эченә ала. Йомгаклаулар күрсәтелгән турлар өчен уртача балл буенча һәр категориядә катнашучыларның ранжированный исемлеген төзеп чыгарыла. Жюри рәисе тарафыннан имзаланган йомгаклау протоколлары Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырыла.

## V. Олимпиаданы үткәрү тәртибе

5.1. Олимпиада 2 этапта үткәрелә: дистанцион һәм йомгаклау турыдан-туры. Олимпиаданың дистанцион этабы Россия Федерациясе субъектларындагы татар иҗтимагый оешмалары каршындагы якшәмбе мәктәпләрендә укучылар (Татарстан Республикасыннан тыш), һөнәри белем бирү оешмалары һәм югары белем бирү мәгариф оешмалары студентлары, чит ил укучылары һәм студентлары өчен үткәрелә.

5.2. Дистанцион этап Интернет-тестлауны һәм дистанцион әңгәмәне үз эченә ала.

5.3. Олимпиаданың дистанцион этабында, әлеге Нигезләмәнең 5.1 пунктында күрсәтелгән, дистанцион этап өчен билгеләнгән «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге порталда теркәлгән укучылар һәм студентлар катнаша ала.

5.4. Интернет-тестлау, дистанцион әңгәмә үткәрү даталары Министрлыкның боерыгы белән раслана, Интернет-тестлау үткәрү өчен портал Оештыру комитеты тарафыннан билгеләнә. Портал, Интернет-тестлау үткәрү даталары турында мәгълүмат Оештыру комитеты тарафыннан өстәмә хат белән һөнәри белем бирү оешмаларына һәм югары белем бирү мәгариф оешмаларына, Россия Федерациясе субъектларындагы татар иҗтимагый оешмалары каршындагы якшәмбе мәктәпләренә җибәрелә.

5.5. Татар теле белемнәре дәрәҗәсен бәяләү максатыннан, дистанцион этап жюри әгъзалары тарафыннан һәр Интернет-тестлау катнашучысы белән дистанцион әңгәмә үткәрелә.

5.6. Интернет-тестлау һәм дистанцион әңгәмә нәтиҗәләре буенча катнашучыларның тәртип белән төзелгән исемлек формалаштырыла. Жюри карары тәртип белән төзелгән исемлек кушымтасы протокол рәвешендә рәсмиләштерелә. Дистанцион этап протоколы имзаланган көненнән алып 7 календарь көне эчендә Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырыла.

5.7. 5.1 пунктында күрсәтелгән һәр категория буенча 1 нче дән 25 нче позициягә кадәр урыннарны алган катнашучылар Олимпиаданың йомгаклау этабына чакырылалар.

5.8. Олимпиаданың йомгаклау этабы тиешле елның апрель аенда Татарстан Республикасында үткәрелә. Олимпиаданың йомгаклау этабы катнашучылары

исемлеге Оештыру комитеты тарафыннан формалаштырыла һәм тиешле елның 10 апреленә кадәр Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырыла.

5.9. Олимпиаданың йомгаклау этабы өч турдан тора:

язма тур (татар теле, татар әдәбияты буенча биремнәрне үтәү);

телдән тур (татар теле һәм татар әдәбияты буенча сорауларга җаваплар);

татар телен һәм татар халкының танылган вәкилләрен популярлаштыруга юнәлтелгән проектларны яклау. Йомгаклау этабының барлык катнашучылары да өч этапны да үтәләр. Проектлар тематикасы Оештыру комитеты тарафыннан билгеләнә һәм катнашучыларга Оештыру комитеты тарафыннан мәгълүмат хатында җиткерелә, шулай ук Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырыла.

5.10. Олимпиаданың язма һәм телдән турлары өчен биремнәр әлеге Нигезләмәнең 3.2 пунктында күрсәтелгән һәр категория өчен аерым эшләнә.

5.11. Олимпиаданың йомгаклау этабының барлык катнашучылары да мәҗбүри рәвештә теркәлү процедурасын үтәләр. Олимпиаданың йомгаклау этабы катнашучыларын теркәү Оештыру комитеты тарафыннан Олимпиада үткәрү урыны буенча гамәлгә ашырыла.

5.12. Олимпиаданың язма туры башланганчы, Оештыру комитеты вәкилләре Олимпиада катнашучыларын инструктаж үткәрәләр: вакыты, куелган баллар белән килешмәү турында апелляцияләр бирү тәртибе, шулай ук үткәрү урынында тиешле тәртипне бозу очраклары (рөхсәт ителмәгән белешмә материаллар, элемтә чаралары куллану), читләштерү очраклары, нәтиҗәләр белән танышу вакыты һәм урыны турындагы мәгълүматны бирәләр.

5.13. Олимпиадада катнашу индивидуаль була, олимпиада биремнәрен катнашучы чит кешеләр ярдәменнән башка мөстәкыйль рәвештә үти.

5.14. Олимпиадада сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән катнашучылар һәм инвалид балалар катнашканда, кирәк булган очракта, Оештыру комитеты, аларның катнашу мөмкинлеген тәэмин итү өчен, сәламәтлек торышын, психофизик үсеш үзенчәлекләрен исәпкә алып, махсус шартлар тудыра.

5.15. Олимпиада катнашучысының ата-аналары (законлы вәкилләре) Олимпиада этабын үткәрү башланганчы кимендә 1 календарь көн алдан әлеге нигезләмә белән танышуларын язма рәвештә раслыйлар һәм балигъ булмаган баланың шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә, «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтында катнашучылар турында мәгълүматларны (алга таба – ризалык) күрсәтеп, нәтиҗәләрне бастыруга язма ризалык бирәләр. Балигъ булган Олимпиада катнашучылары әлеге нигезләмә белән танышуларын раслыйлар һәм Олимпиаданың йомгаклау этабы башланганчы язма ризалык бирәләр. Ризалык Олимпиаданың йомгаклау этабына теркәлү вакытында Оештыру комитетына тапшырыла.

5.16. Олимпиада үткәрү вакытында Олимпиада катнашучылары:

Оештыру комитеты вәкилләре күрсәтмәләрен үтәргә тиеш;

бер-берсе белән аралашырга, аудиториядә ирекле хәрәкәт итәргә хокуксыз;

Олимпиада үткәрү урынында бозу очраклары турында (рөхсәт ителмәгән белешмә материаллары, элемтә чаралары куллану) Оештыру комитетына тиешле тәртипне бозу ачыкланган мәлдә үк, Олимпиада үткәрү урынын калдырмыйча, апелляция бирергә хокуклы.

5.17. Олимпиада биремнәрен үтәүгә бүленгән вакыт тәмамланганчы Олимпиада үткәрү урынында түбәндәгеләр тыела:

катнашучыларга аудиторияләрдән һәм Олимпиада үткәрү урыннарыннан кәгазь һәм (яки) электрон чыганакларда олимпиада биремнәрен, җавап бланкларын һәм черновикларны чыгару, олимпиада биремнәрен күчерү;

Олимпиада катнашучыларына, Олимпиада оештыручыларына, Олимпиада жюри әгъзаларына, Олимпиаданы үткәрү таләпләрендә каралган очраклардан тыш, биремнәр үтәлә торган урыннарда элемтә чараларын куллану.

5.18. Олимпиада катнашучысы Олимпиаданы оештыру таләпләрен бозган очракта, Олимпиаданың Оештыру комитеты вәкиле әлеге Олимпиада катнашучысын аудиториядән чыгара, Олимпиада катнашучысын читләштерү турында акт төзи. Әлеге таләпләрне бозу сәбәпле читләштерелгән Олимпиада катнашучысы агымдагы елда Олимпиадада алга таба катнашу хокукыннан мәхрүм ителә. Аның тарафыннан үтәлгән эш тикшерелми. Әгәр бозу факты Оештыру комитеты вәкилләренә Олимпиаданың йомгаклау этабы тәмамланганнан соң, ләкин йомгаклау нәтиҗәләре расланганчы билгеле булса, катнашучы дисквалификацияләнергә мөмкин, ә аның нәтиҗәсе, катнашучыны дисквалификацияләү турында карар белән жюри протоколы нигезендә, гамәлдән чыгарылырга мөмкин.

5.19. Оештыру комитеты әгъзалары һәм жюри тарафыннан Олимпиаданы оештыру таләпләре бозылган очракта, Оештыру комитеты күрсәтелгән затларны Олимпиада үткәрүдән читләштерә, тиешле акт төзи.

5.20. Язма эшләрне тикшергәннән соң Олимпиада катнашучыларына эшләр күрсәтү үткәрелә.

5.21. Эшләрне күрсәтү тәртибе:

Эшләрне күрсәтүгә бары тик Олимпиадада катнашучылар кертелә.

Эшләргә төзәтмәләр кертү, фотога төшерү, күрсәтү үткәрелә торган аудиториядән тутырылган биремнәр бланкларын (җавап бланкларын) һәм черновикларны чыгару тыела.

Эшләрне күрсәткәннән соң катнашучыларга апелляциягә гариза яза алачак вакыты игълан ителә.

5.22. Апелляцияләрне карау тәртибе:

Апелляция, Олимпиада катнашучысы үзенең олимпиада эшен бәяләү нәтиҗәләре белән килешмәгән очракта, карала.

Апелляцияне карау тәртибе Олимпиада үткәрү башланганчы катнашучыларга һәм аларны озатып баручы затларга җиткерелә. Билгеләнгән формада жюри рәисе исеменә апелляциягә гариза эшләрне күрсәтү тәмамланганнан соң бер сәгать эчендә кабул ителә.

Олимпиада катнашучыларының апелляцияләре жюри һәм Оештыру комитеты белән берлектә карала. Апелляцияне карау тыныч һәм хәерхаклы шартларда үткәрелә. Апелляция биргән Олимпиада катнашучысына аның эшенең тикшерелгән һәм биремнәрне бәяләү критерийлары нигезендә бәяләнгән булуына инану мөмкинлеге бирелә.

Апелляция каралганда шәхесен раслаучы документы белән бары тик гариза биргән катнашучы гына катнаша.

Апелляция карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе чыгарыла:
апелляцияне кире кагу һәм куелган балларны саклау;
апелляцияне канәгатьләндерү һәм баллардагы бәяне үзгәртү.

Олимпиада биремнәрен бәяләү критерийлары апелляция предметы була алмый һәм карауга тиеш түгел.

Апелляция буенча карарлар гади күпчелек тавыш белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, жюри рәисе хәлиткеч тавыш хокукына ия. Апелляция буенча карарлар йомгаклау булып тора һәм яңадан каралырга тиеш түгел.

Апелляцияне карау жюри әгъзалары тарафыннан имзалана торган протокол белән рәсмиләштерелә. Апелляцияләрне карау протоколлары йомгаклау протоколына тиешле үзгәрешләр кертү өчен жюри рәисенә тапшырыла.

5.23. Олимпиаданың телдән туры жюри тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 3.2 пунктында күрсәтелгән һәр категория буенча аерым үткәрелә. Телдән тур жюри әгъзалары белән Олимпиада катнашучысы арасында әңгәмә формасында үтә. Олимпиада катнашучысы җаваплары Оештыру комитеты тарафыннан расланган бәяләү критерийлары буенча бәяләнә. Телдән тур нәтиҗәләре буенча һәр катнашучының нәтиҗәсе жюри әгъзалары тарафыннан телдән тур протоколына кертелә. Телдән тур нәтиҗәләре йомгаклау булып тора һәм яңадан карауга тиеш түгел.

5.24. Проектларны яклау жюри тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 3.2 пунктында күрсәтелгән һәр категория буенча аерым үткәрелә. Олимпиада катнашучыларының проект эшләрен бәяләү өчен критерийлар һәм критерийлар буенча бәяләү бирәмлеге Оештыру комитеты тарафыннан билгеләнә. Проектларны яклау нәтиҗәләре буенча һәр катнашучының нәтиҗәсе жюри әгъзалары тарафыннан проектларны яклау туры протоколына кертелә. Жюриның проектларны яклау нәтиҗәләре буенча карары йомгаклау булып тора һәм яңадан карауга тиеш түгел.

## VI. Олимпиада нәтиҗәләрен чыгару

6.1. Язма, телдән турлар һәм проектларны яклау нәтиҗәләре буенча әлеге Нигезләмәнең 3.2 пунктында күрсәтелгән һәр катнашучылар категориясе буенча катнашучыларның рейтинг исемлеге формалаштырыла. 6.2. Иң күп балл җыйган һәм әлеге Нигезләмәнең 3.2 пунктында күрсәтелгән һәр катнашучылар категориясе буенча рейтинг исемлегендә беренче позицияне алган катнашучылар Олимпиада җиңүчеләре дип билгеләнә. 6.3. Җиңүчеләр арасыннан 3 кеше күләмендә Гран-при иясе билгеләнә: 1 - Татарстан Республикасы катнашучылары арасыннан, 1 - Россия Федерациясенең башка субъектларыннан катнашучылар арасыннан, 1 - чит ил катнашучылары арасыннан. 6.4. Призерлар саны Оештыру комитеты карары белән билгеләнгән квота чикләренә сыеша – һәр категория буенча катнашучылар санының кимендә 15% ы. Жюри карары буенча призерлар саны күбрәк булырга мөмкин. Әгәр Олимпиада катнашучысы, билгеләнгән квота чикләрендә призер буларак билгеләнеп, рейтинг исемлегендә аннан соң килгән катнашучылар белән бер үк күләмдә балл туплаган булса, әлеге катнашучы һәм аның белән тигез балл җыйган барлык катнашучылар турында карар телдән тур нәтиҗәсе буенча билгеләнә.

## VII. Олимпиада җиңүчеләрен һәм призерларын бүләкләү

7.1. Гран-при иясе, Олимпиада җиңүчеләре һәм призерлары Министрлыкның дипломнары һәм түбәндәге күләмдә акчалата премияләр белән бүләкләнә: Гран-при ияләре – 80 000 сум; җиңүчеләр – 65 000 сум; призерлар – 50 000 сум.

7.2. Призерлар, җиңүчеләр һәм Гран-при ияләрен әзерләгән укытучылар акчалата премияләр белән бүләкләнә: Гран-при ияләрен әзерләгән укытучылар – 50 000 сум; җиңүчеләрне әзерләгән укытучылар – 40 000 сум; призерларны әзерләгән укытучылар – 30 000 сум.

7.3. Һәр Олимпиада катнашучысына катнашучы дипломы бирелә.

## IX. Олимпиаданы финанслау

9.1. Олимпиаданы финанслау Дәүләт программасы кысаларында һәм Министрлыкның җыелма сметасыннан гамәлгә ашырыла.